КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 март г.Казань № 269

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 3 декабрь, 943 нче карары белән расланган «2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2024 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 3 декабрь, 943 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 ноябрь, 829 нчы; 2019 ел, 20 май, 409 нчы; 2019 ел, 2 сентябрь, 760 нчы; 2020 ел, 6 июль, 556 нчы; 2020 ел, 5 ноябрь, 997 нче; 2021 ел, 20 август, 754 нче; 2021 ел, 20 август, 754 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1329 нчы; 2022 ел, 26 август, 905 нче; 2023 ел, 3 февраль, 88 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасына (алга таба – программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

программа паспортының «Программаны төп әзерләүчеләр» юлындагы беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

программаның IV бүлегендәге беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин